**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

_______________ №________________

Гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 11 апрелендәге №16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 23нче маддәсенә ярашлы рәвештә боерам:

1. Гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына мөрәҗәгатьләрен анализлауның теркәлгән тәртибен расларга.

2. Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге (Н.И.Коннова) гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә елга ике мәртәбә, яртыеллыктан соң килгән аеның 15енә кадәр, анализ ясарга тиеш.

3. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге (А.Г.Сафин) анализны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына яртыеллыктан соң килгән айның 15еннән дә соңга калмыйча урнаштырырга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны эшләр идарәчесе Н.И.Латыйповка йөклим.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы юстиция министры боерыгы белән расланган
«___» _________2015 ел
№________________ ___

Гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе

1. Әлеге Тәртип “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 11 апрелендәге №16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 23нче маддәсенә яраклаштырып әзерләнгән һәм гражданнарның һәм оешмаларның Татарстан Ресубликасы Юстиция министрлыгына (алга таба – министрлык) мөрәҗәгатьләрен (алга таба – мөрәҗәгать) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Анализлаганда кабул ителгән, икенче урынга адресланган һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документ әйләнеше формасындагы мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итергә вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итүләр, мөрәҗәгатьләрен тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар, шул исәптән, кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан электрон документ әйләнеше һәм әлеге Тәртипнең 4нче һәм 5нче пунктларына яраклаштырып бирелгән мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Министр, министрның беренче урынбасары, министрның урынбасарлары, эшләр идарәчесе (алга таба – Министрлык) кабул иткәндәге мөрәҗәгатьләр турында мәгълүматны Бүлеккә җитәкчелек кабул итүе вакытында гражданнарны язып барган белгеч тапшыра.

5. Күчмә кабул итүләр турында мәгълүматны Бүлеккә Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлеге тапшыра.

6. Әлеге Тәртипнең 4нче һәм 5нче пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны җаваплы хезмәткәр Бүлеккә яртыеллыктан соң килгән айның 10нчы көненә кадәр тапшыра.

7. Бүлек мөдире әлеге Тәртипнең 3нче пунктында күрсәтелгән, шулай ук, 4нче һәм 5нче пунктына яраклаштырып тәкъдим ителгән мәгълүматны ике эш көне

дәвамында гомумиләштерә һәм анализлый да, министрлыкның эшләр идарәчесе белән килештерә.

8. Мөрәҗәгатьләрнең анализы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыру өчен Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә җибәрелә. Анализ яртыеллыктан соң килгән айның 15еннән дә соңга калмыйча министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

9. Министрлыкка гражданнарның мөрәҗәгатьләре Министрлыкның рәсми сайтында ачык мәгълүмат булып тора. (http://minjust.tatarstan.ru).